**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6828**
**20.11.2018**

Хаким Кубогына бокс буенча Яр Чаллы шәһәре чемпионатына һәм беренчелегенә әзерлек һәм аны үткәрү турында

Шәһәр Советының «Раслау турында» 2008 елның 25 сентябрендәге 34/18 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре Хакиме Кубогын гамәлгә кую тәртибе турында нигезнамә нигезендә, Башкарма комитетның 2016 елның 2 ноябрендәге 5769 нчы карары белән расланган «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсенә Хаким Кубогына бокс буенча Яр Чаллы шәһәре чемпионатын һәм беренчелеген (алга таба – ярышлар) 2018 елның 15 декабрендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) ярышларга әзерлек һәм аларны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 1 нче кушымтада каралганча;

2) ярышларга әзерлек һәм аларны үткәрү буенча чаралар планын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) ярышларны үткәрү турында нигезнамәне, 3 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә ярышларга әзерлек һәм аларны үткәрү чыгымнарын финанслауны 2018 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Массакүләм спорт» 11.02 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 155 400,00 сум (йөз илле биш мең дүрт йөз) сум 00 тиен күләмендә, 4 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 20 ноябрендәге
6828 нче карарына
1 нче кушымта

Ярышларга әзерлек һәм аларны үткәрү буенча оештыру комитеты составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Хәлимов Р.М. | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Насрединов Р.М. | оештыру комитеты рәисе урынбасары, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе башлыгы |
| оештыру комитеты әгъзалары: | | |
| 3. | Закиров Н.Д. | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| 4. | Кыямов Р.Ә. | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 5. | Кузнецов А.С. | «Витязь» БЯСМ» МАӨББУ директоры |
| 6. | Минегалиев М.Х. | Башкарма комитетның җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 7. | Мөхәммәтҗанова Р.Р. | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |
| 8. | Ногманова Э.И. | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 9. | Солтанова Р.К. | Башкарма комитет икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге башлыгы |
| 10. | Фатыйхов Н.Ш. | ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешенү буенча) |
| 11. | Харисов В.Х. | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| 12. | Хафизов Р.Х. | «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» МАУ директоры |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2018 елның 20 ноябрендәге
6828 нче карарына
2 нче кушымта

Ярышларга әзерлек һәм аларны үткәрү буенча чаралар
планы

| Т/с | чараларның исеме | үтәлү срогы | үтәү өчен җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Оештыру комитеты киңәшмәсен үткәрү | 11.12.2018 кадәр | Насрединов Р.М. |
| 2. | Пресс-релиз әзерләү, афишалар ясау һәмябыштыру | 11.12.2018 кадәр | Насрединов Р.М. |
| 3. | Судьялар бригадасын һәм хезмәт күрсәтүче персоналны комплектлаштыру, судьялар һәм командаларның вәкилләре белән киңәшмә үткәрү, ярышларда судьялар эшен тәэмин итү | 15.12.2018 | Насрединов Р.М. |
| 4. | Ярышлар үткәрү урынын (боксчылар рингы урнаштыру), кирәкле инвентарь һәм атрибутика әзерләүне тәэмин итү | 15.12.2018 | Насрединов Р.М. |
| 5. | «Витязь» БЯСМ спорт комплексын бәйрәмчә бизәүне тәэмин итү, катнашучылар, судьялар өчен кирәкле бүлмәләр, җиһазлар, мактаулы кунаклар өчен бүлмә әзерләү, баннерлар урнаштыру | 15.12.2018 | Насрединов Р.М. |
| 6. | Сценарий һәм алып баручыларны әзерләү, ярышларны ябу тантанасында артистлар чыгышын тәэмин итү | 15.12.2018 | Ногманова Э.И.<br>Насрединов Р.М. |
| 7. | Ярышларның, аларны ачу һәм ябу тантаналарының музыкаль бизәлешен, тавыш яңгырашын тәэмин итү | 15.12.2018 | Насрединов Р.М. |
| 8. | «Витязь» БЯСМ спорт комплексына керү юлларын, автотранспорт кую урыннарын чистарту үткәрү | 15.12.2018 | Кыямов Р.Ә. |
| 9. | Ярышларда җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү | 15.12.2018 | Минегалиев М.Х. |
| 10. | Ярышларны үткәрү урыннарында туклануны оештыру | 15.12.2018 | Солтанова Р.К. |
| 11. | Ярышларның барышын һәм йомгакларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештыру | 15.12.2018 | Мөхәммәтҗанова Р.Р. |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2018 елның 20 ноябрендәге
6828 нче карарына
3 нче кушымта

Хаким Кубогына бокс буенча
Яр Чаллы шәһәре чемпионатын һәм беренчелеген үткәрү турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Хаким Кубогына бокс буенча Яр Чаллы шәһәре чемпионаты һәм беренчелеге (алга таба – ярышлар) түбәндәге максатларда үткәрелә:

1) сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
2) шәһәрдә боксны популярлаштыру;
3) спорт осталыгын күтәрү;
4) көчле спортчыларны ачыклау;
5) Татарстан Республикасы беренчелегендә катнашу өчен шәһәрнең җыелма командасын формалаштыру.

2. Ярышларны үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә. Оештыру комитеты судьялар коллегиясен формалаштыра.

2 бүлек. Ярышларны үткәрү сроклары

3. Ярышлар 2018 елның 15 декабрендә «Витязь» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесендә үткәрелә. Беренчел ярышлар 2018 елның 13 һәм 14 декабрендә «Төзүче» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесендә үткәрелә .

4. Катнашуга табиб тарафыннан расланган заявкалар баш судьялар коллегиясенә 2018 елның 5 декабренә кадәр stadion79@list.ru электрон почтасы аша яки Габдулла Тукай исемендәге яр буе, 16 йорт адресына, түбәндәге форма буенча җибәрелә:

Хаким Кубогына бокс буенча
Яр Чаллы шәһәре чемпионатында һәм беренчелегендә катнашуга
заявка

| Т/с | Катнашучыларның Ф.И.А.и. | Учреждение | Үлчәү категориясе | Туу датасы | Гомерем һәм сәламәтлегем өчен шәхсән җавап бирәм (шәхси имза) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |

Җаваплы вәкилнең Ф.И.А.и., элемтә телефоны ________________

## 3 бүлек. Ярышларны үткәрү шартлары

5. Шәхси-команда ярышлары Олимпия системасы буенча, гамәлдәге бокс кагыйдәләре нигезендә үткәрелә.

6. Ярышларга тиешле спорт әзерлеге һәм медицина рөхсәте булган түбәндәге үлчәү категорияләрендәге шәһәр спортчылары кертелә:

- 2005-2006 елларда туган үсмерләр: 38,5 кг, 40 кг, 41,5 кг, 43 кг, 44,5 кг, 46 кг, 48 кг, 50 кг, 52 кг, 54 кг, 56 кг, 59 кг, 62 кг, 65 кг, 68 кг, 72 кг, 76 кг, 76 кг авыррак;
- 2003-2004 елларда туган өлкәнрәк үсмерләр: 46 кг, 48 кг, 50 кг, 52 кг; 54 кг; 57 кг; 60 кг; 63 кг; 66 кг; 70 кг; 75 кг; 80 кг; 80 кг авыррак;
- 2001-2002 елларда туган яшүсмерләр: 49 кг; 52 кг; 56 кг; 60 кг, 64 кг, 69 кг, 75 кг, 81 кг; 91 кг; 91 кг авыррак.

7. Команда зачеты барлык яшь төркемнәре буенча һәр үлчәү категориясендә командаларның барлык нәтиҗәләренең баллар суммасы белән билгеләнә.

I урын – 7 очко, II урын – 5 очко, III урын – 3,5 очко.

Иң күп очко җыйган команда 1 урынны ала һәм башкалар.

## 4. Ярышларда катнашучыларны бүләкләү

8. Ярышларның йомгаклары буенча һәр үлчәү категориясендә җиңүчеләр һәм призерлар – грамоталар һәм медальләр, җиңүче команда күчмә Кубок белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы — Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2018 елның 20 ноябрендәге
6828 нче карарына
4 нче кушымта

Ярышларны
оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар
сметасы

| учреждение | чыгымнар статьясы | күләм күрсәткечләре | берәмлек бәясе, сумнарда | барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| Яр Чаллы шәһәренең «Төзүче» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе | 1) ашыгыч ярдәм хезмәтләре күрсәтү | 1 машина х 4 сәгать | 2 600 | 10 400 |
| | 2) тавыш аппаратурасын арендалау (ут, тавыш аппаратурасы) | 4 сәгать | 20 000 | 80 000 |
| | 3) басма продукция | 1500 данә | 20 | 30 000 |
| | 4) баннер ясау | 2 данә | 10 000 | 20 000 |
| | 5) актив катнашучыларны бүләкләү | 3 кеше | 5 000 | 15 000 |

Смета буенча барлыгы: 155 400,00 сум (йөз илле биш мең дүрт йөз) сум 00 тиен.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева